ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, 1, с.Большие Яки,
Зеленодольский район, 422524

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЖӘКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мэктэп ур., 1, Олы Яке ав,
Зеленодольск районы., 422524

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# БОЕРЫК

2020 елнын 31 гыйнвары №1

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Олы Җәке авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2019 елнын 28 мартындагы 50 нче карары 2020 елнын 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт (зур Җәке КФҮ бинасы), Каратмән авылы Клуб урамы, 23 нче йорт (Каратмән авыл клубы бинасы), Уразлы авылы Дуслык урамы, 3 нче йорт (Уразлы авыл клубы бинасы).

4.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Олы Җәке авыл жирлеге башлыгы** **Ф.А.Фәйзуллина**

Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнвары №1 карарына 1 нче кушымта

ТР Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә 2020 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3337,75 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 950,81 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1836,30 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнвары №1 карарына 2 нче кушымта

ТР Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә 2020 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 589,69 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2748,06 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 950,81 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1836,30 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |